<table>
<tr>
<td>ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН</td>
<td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ</td>
</tr>
</table>

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2019 елның 17 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарылырга тиешле сорауны расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән кала, 500 сум күләмендә үзара салым тапшыру һәм аларны түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

I. Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту:

- Ивановка авылында (Үзәк, октябрь, яшьлек, Заречная, Нагорная, Энтузиастлар, Чишмә, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту;);

- Ивановка авылында (Родничная ур., Мәктәп тыкрыгы, яшьлек ур., 1) җирле әһәмияттәге юлларга вак таш җәю.

II. Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- Родничная урамындагы чишмәне төзекләндерү (каптаж).

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Ивановка авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева